КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № 865

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2021 ел, 3 март, 116 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2021 ел, 3 март, 116 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка «(алга таба – алына торган җир кишәрлекләре)» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, шул исәптән 3 223 кв.метр мәйданлы һәм 16:33:080702:38 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 15 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген һәм 2 949 кв.метр мәйданлы һәм 16:33:080702:380 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 529 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә алыштыру юлы белән»;

3 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлекләре өчен каплау күләмен билгеләп, 3 223 кв.метр мәйданлы һәм 16:33:080702:38 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 15 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең, 2 949 кв.метр мәйданлы һәм 16:33:080702:380 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 529 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең базар кыйммәтен бәяләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешү),

җир кишәрлекләрен алыштыру шартнамәләрен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;»;

җиденче абзацка «килешүләр» сүзеннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«һәм шартнамәләр»;

унынчы абзацта «имзаланган килешүләр» сүзләреннән соң «һәм шартнамәләр» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин